СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.06.2020 № 41/6
На № _________ от _____________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең генераль планын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-32 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге генераль планы проектына 2020 елның 23 мартындагы 10-53/3706 номерлы Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин кул куйган бәяләмә, 2018 елның 24 декабрендәге Борды авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикы  Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең генераль планын расларга.
2. Борды авыл җирлеге Советының 2012 елның 9 ноябрендәге 23/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең генераль планын барлык үзгәрешләре белән юкка чыгарырга.
3. Борды авыл җирлеге Советының 2014 елның 15 декабрендәге 46/6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең генераль планын барлык үзгәрешләре белән юкка чыгарырга.
4. Борды авыл җирлеге Советының 2012 елның 9 ноябрендәге 23/2 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Борды авыл җирлеге Советының 2014 елның 15 декабрендәге 46/6 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Р.И. Закиров